| | |
|---|---|
| СОВЕТ НОРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«8» июль 2021 ел № 32

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 12.03.2021 елда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы 27 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Урман кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон, 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Әйләнә-тирә мөхитне саклау турында»гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 12.03.2021 елда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы 27 нче номерлы карарына (31.03.2021 ел № 28 үзгәрешләр белән) (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарнын атамасын “физик һәм юридик затлар милкендә булган җирләр” сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. Карар белән расланган, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәдә:

1) нигезләмәнең исемен “физик һәм юридик затлар милкендә булган җирләр” сүзләре белән тулыландырырга;

2) 2.2.2, 2.4, 3.3.1 - 3.3.7, 3.5, 3.14, 3.16, 3.17 һәм 3.18 пунктларын төшереп калдырырга;

3) 2.3 пунктта «милекчеләр» сүзен төшереп калдырырга;

4) 3.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Агач һәм куаклар кисүгә, кронлауга һәм утыртуга рөхсәт, гариза бирү көнен дә кертеп, 13 көн эчендә бирелә.»;

5) 3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Рөхсәт бирү гариза бирүченең салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычы булмаганда, Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиеш (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш).»;

6) 3.11 пунктта «рөхсәт ителергә мөмкин» сүзләрен «рөхсәт ителә» сүзенә алмаштырырга.

7) 3.13 пунктта «№ 2 кушымта нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) № 1 һәм № 2 кушымталарын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгы Шарипжанов Радик Наиловичка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы — Р.Н. Шарипҗанов